**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«15» декабрь 2025 ел** **№ 22**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын даими нигездә биләүче затларны иминиятләштерү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләүче затларны иминиятләштерү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 04 мартындагы 133 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларны даими нигездә иминиятләштерү тәртибе һәм шартлары турында кушымта итеп бирелә торган нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башлыгы урынбасары И. Н. Захаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев